КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 май г.Казань № 440

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 70 нче; 2022 ел, 11 февраль, 118 нче; 2022 ел, 8 апрель, 329 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарның 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү (сатып алуларны оештыру) | 120 100 000,0»; |

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда һәм аларның күләмнәрендә:

4.1 пунктның 4 графасында «2 036,15» саннарын «2 525,02» саннарына алмаштырырга;

4.3 пунктның 4 графасында «27,88» саннарын «40,21» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин